ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ СПАССКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

№216

КАРАР

"30" 03 2022 ел

Спас муниципаль районы бюджетыннан 2017 елның 20 декабрендәге 895 номерлы карары (2019 елның 16 маендагы 335 номерлы үзгәрешләр белән) белән расланган район үзәгеннән 11 чакрым ерак һәм аз халыклы авыл пунктларына беренче чиратта кирәкле товарларны китерү белән бәйле кулланучылар кооперациясе оешмалары чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында һәм 2022 елда Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү турында» 2021 елның 29 ноябрендәге 384-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Спас муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2017 елның 20 декабрендәге 895 номерлы карар белән расланган район үзәгеннән 11 чакрым ераклыкта урнашкан ерак һәм аз торак авыл пунктларына товарларны китерү белән бәйле кулланучылар кооперациясе оешмаларының чыгымнары өлешен каплауга Спас муниципаль районы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә (2019 елның 16 маендагы 335 номерлы үзгәрешләр белән):

1.1. Тәртипнең 2.9 п. пунктында «субсидия бирүчегә, һәм дәүләт (муниципаль) финанс контроле органнарына субсидияләр бирү шартларының, максатларының һәм тәртибенең үтәлешен тикшерүләрне» сүзләрен «субсидияләр бирүчегә һәм Бюджет кодексының 78 статьясындагы 3 пунктының 5 бүлегендә каралган тикшерүләрне муниципаль финанс контроле органнарына» сүзләренә алмаштырырга;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының рәсми сайтында, хокукый мәгълүматның рәсми сайтында урнаштырырга (//http:pravo.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны ТР Спас муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасарына йөкләргә.

Спас муниципаль районы
Башкарма комитетының җитәкчесе
вазифаларын башкаручы: Е.В. Савинов